ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 13 » март 2020ел № 170

**Арча муниципаль районы башкарма комитетының 2018 елның 13 декабрендәге 1227 номерлы «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының бердәм дежур-диспетчерлык хезмәте турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

"Россия Федерациясендә мәгариф турында" 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Федераль законга туры китерү максатыннан, Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Арча муниципаль районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының бердәм дежур-диспетчерлык хезмәте турында» 2018 елның 13 декабрендәге 1227 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының бердәм дежур-диспетчерлык хезмәте турындагы Нигезләмәгә (1 нче кушымта) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 3.2.8 пунктның 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2.8. Бердәм дежур-диспетчерлык хезмәтенең оператив дежур торучысына таләпләр:

эш стажына таләпләр куелмыйча урта һөнәри белем яисә белгечлек буенча кимендә 3 ел эш стажы».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә (http://arsk.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Башкарма комитет житәкчесе И.Ә. Галимуллин